III төбәкара олимпиададасында барлыгы 140 укучы катнашкан.
Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгынын төбәкара хезмәт-тәшлек секторы житәкчесе Голия Мусина әйтvенчә, быел катнашучылар саны ике мәртәбә диярлек арткан. Оч ел элек аларнын саны 80 булган. Башкортстан Республикасы, Әстерхан, Саратов, Тvбән Новгород, Курган, Томән шәһәрләре кебек 22 төбәктән килгәннәр. «Олимпиадага беренче тапкыр Красноярск һәм Новосибирск укучылары да кушылды. Чара чит төбәкләрдән килгән яшьләрне дуслаштыруны кvздә тота. Алар, ойләренә кайткач, социаль челтәрләрдә аралашуын дәвам итә», – ди белгеч. Биремнәргә килгәндә, сораулар төбәкләрдәге укыту vзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән. Укучылар татар теле һәм әдәбиятыннан белемнәрен, сәнгатьле сойләм осталыгын кvрсәткән. Шулай, III төбәкара олимпиадада Мордовиядән дә жинvчеләребез бар. Әдәбият буенча призерлар: Карабанов Тимерлан (8 кл.), Ләмберә районы, Черемиш мәктәбе; Алукаева Эльвина белән Муртазина Карина (9 кл.), Ләмберә районы, Татар Тавла мәктәбе укучылары; Аберхаева Мәрьям (9 кл.), Ромодан районы Белозерье мәктәбе; Сюбаев Адель (10 кл.), Ләмберәнен беренче мәктәбе; Чугунова Камила (10 кл.), Рузаевка районы Татар Пешлә мәктәбе.
Татар теле буенча призерлар: Биксаляева Диана (8 кл.), Рузаевка районы Татар Пешлә мәктәбе; Абудкина Жасмин (11кл.), Кадошкино районы Латышовка мәктәбе.
Ижади конкурсында жинvчеләребез: Бадамшин Марат (10 кл), Кадошкино районы Большие Поляны мәктәбе; Сюбаева Алсу (11кл.), Ләмберә районы Пензятка мәктәбе.
Укучыларны һәм укытучыларын котлыйбыз!
«Ватаным Татарстан» газетасы журналисты Сәрия Мифтахова Мордовия Республикасынын Ләмберә районындагы Татар Тавла мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы Әлфия Мортазинадан интервью ала һәм анын vзе белән Казанда vткән төбәкара олимпиадасына ун укучы алып килгән икәнлеге турындагы мәкаләсендә яза. Тагы сонгы биш елда халыкара олимпиадада да катнашулары турында сораштыра. «...Шәһәр мәктәпләрендә татар теле укытылмаса да, авылларда татар телен атнага – ике, әдәбиятны бер сәгать ойрәнәләр. Педагогия институтында да татар телен ойрәнv момкинлеге бар. Әлфия Мортазина vзе дә шунда белем бирә», - дип яза «Унайсыз шул безгә...», - дигән мәкаләсендә.
Ә Әлфия Муртазина интервьюсында: «...Телнен бvген авыр хәлдә калуын укучылар яхшы анлый. Шуна кvрә татарча сойләшергә тырыша. Әмма арада башка берәр милләт кешесе булса, унайсыз булмасын дип, урысчага кvчәләр. Татар телен әти-әниләр гаризасы буенча укытабыз. Берәv дә татарча укытырга каршы килмәде. Кыргыз, урыс,

әзәрбайжан милләт вәкилләре дә бик теләп ризалаштылар, – ди могаллимә. – Кызганыч, гаиләләрдә кvбрәк урысча сойләшә башладылар. Мәктәптә туган як тарихын ойрәтәм, драма тvгәрәге алып барам. Гаилә белән мәктәп бердәм булганда, телне саклап кала алырбыз дип ышанам».

Олимпиадада катнашучылар буш вакытларда татарча спектакль карап, ижат әһелләре белән дә очрашкан. Жинvче, призерлар дипломнар, бvләкләр алганнар. Ә халыкара бәйге 22 – 25 апрельдә vтәчәк.